Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

Укытучылар өчен методик кулланма



9

«Татармультфильм»

Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ»

## 9 нчы сыйныф

**Укытучылар өчен методик кулланма**

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителә*

Казан
2025

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)
Х18

Фәнни редакторы
**Р. З. Хәйдәрова,** педагогика фәннәре кандидаты, доцент

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всего издания или его части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хайдарова, Р. З. и др.**
Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 9 класс: методическое пособие для учителя к учебнику для общеобразовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина. – Казань: Татармультфильм, 2025. – 44 с.

ISBN 978-5-906508-50-8

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)

ISBN 978-5-906508-50-8

© «Татармультфильм» нәшрияты, 2025
© Хәйдәрова Р. З., Әхмәтҗанова Г. М., Гыйниятуллина Л. Ә., 2025

## 9 нчы сыйныфта «Татарстан Республикасы дәүләт (татар) теле» фәнен укыту өчен төзелгән укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре

Федераль дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле юнәлеш (системно-деятельностный подход),** ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик күрсәтмә рус телле балаларга татар теле укыту системасын оештыруның да нигезе булып тора.

Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар телен дәүләт теле буларак укытуның төп максаты – укучыларның рухи һәм әхлакый үсешен тәэмин итү, аларның күпмилләтле җәмгыятьтә милләтара мөнәсәбәт культурасын формалаштыру, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыру, татар телен дәүләт теле буларак укыту телне **аралашу** чарасы буларак үзләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә **үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек** итү күнекмәләрен формалаштыру. Шулай ук укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү; уку эшчәнлеген оештыруның нигезе булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, аларны мөстәкыйль уку эшчәнлегенә әзерләү.

Татарстан Республикасы мәктәпләре өчен төп гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен укытуга **372 сәгать** вакыт бирелә. Базис укыту планында 9 нчы сыйныфта атнага 3 сәгать исәбеннән **102 сәгать** каралган.

9 нчы сыйныфта укучы рус телле балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты (УМК) түбәндәге компонентлардан тора:

1. Дәреслек.
2. Укытучы өчен методик ярдәмлек:
   – календарь-тематик план;
   – ишетеп аңлау күнегүләре;
   – контроль-үлчәм материаллары.

УМКга эчтәлек сайлау Россия мәгариф министрлыгының 18.05.2023 елгы 372 номерлы «Төп гомуми белем бирүнең федераль белем бирү программасын раслау турында»гы боерыгына (теркәлү вакыты: 12.07.2023 ел, №74229) һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына нигезләнде**.**

**Телне аралашу аша өйрәнү принцибы** нигезендә УМК өчен материал укучыларның яшь үзенчәлекләреннән, теләк-омтылышларыннан, аралашу ихтыяҗларыннан чыгып сайланды.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: «Без Татарстанда», «Һөнәр сайлау», «Сәламәтлек – зур байлык», «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый». Тематик планнарда темаларның эчтәлеге киңәйтелеп, федераль эш программасына тәңгәллеге күрсәтелеп барылды.

**Телне функциональ төстә өйрәнү принцибының** төп эчтәлеге – лексик-грамматик материалның академик тәртиптә бирелмичә, ә коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнүе.

Федераль эш программасына нигезләнеп, дәреслектә грамматик материал түбәндәгечә бирелде һәм, аралашу өчен морфология бүлегенең аеруча әһәмиятле икәнен истә тотып, нигездә 5–8 нче сыйныфларда өйрәнелгән сүз төркемнәрен һәм шулай ук гади җөмлә синтаксисын кабатлауга игътибар ителде.

– юклык алмашлыклары: *беркем, бернәрсә, беркайчан*;

– сорау алмашлыклары: *ни өчен?, нигә?, ник?*;

– урын рәвешләре: *ерак, якын*; охшату-чагыштыру рәвешләре: *яшьләрчә, заманча, батырларча*;

– боерык фигыльнең III зат берлек һәм күплек сандагы барлык һәм юклык формалары (барсын! – барсыннар! – ба́рмасын! – ба́рмасыннар!);

– җөмләнең тиңдәш кисәкләре, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре;

– җыючы теркәгечләр *һәм, да (дә), та (тә)* һәм санау интонациясе.

Синтаксис бүлеге буенча, куллану ешлыгына нигезләнеп, түбәндәге кушма җөмлә төрләре дәреслектә урын алды:

– теркәгечле тезмә кушма җөмләләр: *һәм, ә, ләкин, да (дә), та (тә), яки*;

– иярчен вакыт җөмләле кушма җөмләнең *-гач (-гәч), -кач (-кәч)* кушымчалары ялганып ясалган синтетик тибы;

– иярчен сәбәп җөмләле кушма җөмләнең *чөнки* теркәгече, *шуңа күрә* мөнәсәбәтле сүзе ярдәмендә ясалган аналитик тибы;

– иярчен шарт җөмләле кушма җөмләнең *әгәр* теркәгече һәм *барса, килсә* шарт фигыльләре ярдәмендә ясалган синтетик тибы.

Күрсәтелгән эчтәлектән тыш, алдагы сыйныфларда өйрәнелгән лексик-грамматик материал даими рәвештә кабатланып барылды.

Рус телле балаларны татар сөйләменә коммуникатив технология нигезендә өйрәтү **дәреслекләренең төзелеше цикллылыкка** корылган. **Цикл – уку материалын диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр.** Ягъни өйрәнелгән лексик-грамматик материал, тану дәрәҗәсендә генә калмыйча, сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелергә тиеш. Дәрес тибы буенча бу дәресләр **лексик күнекмәләр формалаштыру дәресләре** (ЛКФ) һәм **грамматик күнекмәләр формалаштыру дәресләре** (ГКФ), **лексик, грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре** (ЛГКК), **диалогик/монологик сөйләм дәресләре** (Д/МС) дип атала. Бу дәресләр циклында өйрәнелгән лексика һәм грамматика турыдан-туры текстта кабатлана, төрле бәйләнешләргә керә, ягъни лингвистик материалны сөйләмдә куллану камилләшә. Тексттан соң булган этапта текст эчтәлеге буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм – **татарча аралашу этабына чыгалар**.

Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнүдә күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Шуңа күрә дәреслектә эчтәлекне мөстәкыйль сөйләмгә җиткерү өчен сөйләми (речевые) күнегүләр: диалоглар, ситуатив күнегүләр, иҗади биремнәр еш кулланылды. Дәреслектәге күнегүләрдән тыш, укытучылар түбәндәге методик ярдәмлеккә мөрәҗәгать итә алалар: «Мин татарча сөйләшәм. Я говорю по-татарски». Сборник ситуативных упражнений для русскоязычных учащихся. Авт.: Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. Наб. Челны, 2019.

Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуы тәэмин ителә.

Укучыларның сөйләми активлыгын булдыруда шулай ук уку эшчәнлеген оештыруның **эш режимнарын** дөрес оештыру да бик мөһим. Дәреслектә Федераль дәүләт стандартларының таләпләренә туры килгән **парларда, төркемнәрдә, индивидуаль эшләү өчен биремнәр** һәм **иҗади биремнәр** киң урын алды. Алар дәреслектә аерым шартлы билгеләр белән күрсәтелә бардылар.

Укытучы өчен **методик ярдәмлеккә** ишетеп аңлау күнегүләре (аудирование), федераль эш программасы нигезендә төзелгән календарь-тематик план, һәр тема буенча контроль һәм үзконтроль материаллары кертелде.

1) **Ишетеп аңлау күнегүләре** – һәр дәрестә, дәреснең төрле этапларында кулланылырга тиешле сөйләм эшчәнлеге. Ишетеп аңлау күнегүләренә таләпләр федераль эш программасында киң яктыртылу сәбәпле, методик ярдәмлектә дәрес темалары буенча күнегүләрнең үзләрен бирү белән чикләнелде.

2) Тәкъдим ителгән **тематик план** ел дәвамында өйрәнәсе материалның дәресләргә бүленешен күрсәтә. Һәр дәреснең коммуникатив максаты тематик планда аерым графада күрсәтелә барды, шуңа күрә дәрес планы, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, аңа игътибар итү аеруча мөһим.

Федераль эш программасы бүлекләренең эчтәлеге тулысынча дәреслеккә һәм тематик планга салынды, аның үтәлеше күрсәтелә барды. Федераль эш программасы бүлекләренең эзлеклелеге белән дәреслектәге, тематик пландагы эчтәлек бирелеше эзлеклелеге тәңгәл килмәгән очракта да, **дәреслектәге һәм тематик пландагы дәресләр бирелешенең эзлеклелеген алыштырырга тәкъдим ителми**, чөнки федераль эш программасы нигезендә төзелгән дәреслек эчтәлегенең үзара бәйләнеше, системалылыгы бозыла.

3) Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе – укучыларның белемен **контрольгә** алу. Билгеле булганча, контроль укыту барышын көйли, ягъни контрольгә карап, укытучы үз эшчәнлеген оештыра. Методика фәне билгеләгәнчә, укучыларның ятлаганны сөйли белүләре, аерым сүзләрне, җөмләләрне тәрҗемә итә белүләре яисә грамматик категорияләрне аңлый алулары гына **контроль объекты** була алмый. Контрольнең төп объекты булып, укучының өйрәнелгән лексиканы һәм грамматиканы кулланып, **мөстәкыйль аралаша алуы** тора. Календарь-тематик планның коммуникатив максат графасында дәресләр өчен күрсәтелгән **предмет нәтиҗәләре – тема буенча сөйләшә белү күләме** укучыларның белем дәрәҗәләрен контрольгә һәм үзконтрольгә алуның да эчтәлеге булып тора ала. Дәрес планнары төзегәндә, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, бу графага игътибар итү аеруча мөһим.

## Календарь-тематик план

| Дәрес номеры | Дәрес темасы | Дәреснең коммуникатив максаты |
|---|---|---|
| **Татарстан икътисады (11 сәгать)<br>IV. Моя Родина** | | |
| 1–3 | Без Татарстан Республикасында яшибез.<br>Татарстанның территориясе, чикләре, халыклар дуслыгы, атрибутикасы | Текстны сәнгатьле уку. Татарстанның табигате, территориясе, чикләре, шәһәрләре турында сөйли, диалоглар төзи белү.<br>Халыклар дуслыгын, Татарстанның, Россиянең атрибутикасы турында сөйли белү |
| 4–5 | Татарстанның икътисади үсеше.<br>Татарстанның зур үсешкә ирешкән промышленность тармаклары | Татарстанда промышленность тармакларын әйтә, иң үскән юнәлешләрен сөйли белү |
| 6–8 | Татарстанның фәнни-техник яктан үсеше.<br>Татарстан Республикасында технопарклар челтәре | Татарстан Республикасында технопарклар челтәрен әйтә белү. Республиканы фәннитехник яктан үстерү буенча дәүләт программасын сөйли белү |
| 9–11 | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре.<br>Татарстан – кара алтын республикасы.Татарстанда нефть чыгару тарихы, районнары | «Татарстан – кара алтын республикасы» текстындагы лексик-грамматик материалны истә калдыру. Тексттан кирәкле мәгълүматны таба белү.<br>Татарстанда нефть чыгару турында белешмә бирә белү. Җөмлә кисәкләрен билгели белү күнекмәләрен ныгыту |
| **Татарстан сәнгате (28 сәгать)<br>IV. Моя Родина** | | |
| 12–14 | Татарстанда яшәгән күренекле мәдәният эшлеклеләре.<br>Татар милли сәнгатенең дөньякүләм урыны.<br>Татарстан территориясендә урнашкан тарихи истәлекләр | Татарстанда яшәгән күренекле мәдәният эшлеклеләре, татар милли сәнгатенең дөньякүләм танылуы турында сөйли, диалоглар төзи белү.<br>Татарстан территориясендә урнашкан тарихи истәлекләр турында белешмә бирә белү.<br>Казанда туризм үсеше турында сөйли белү |
| 15–16 | Кушма җөмлә.<br>Беренче татар китаплары.<br>Без китапханәдә | Тезмә кушма җөмлә, иярченле кушма җөмлә төрләрен аера белү.<br>Татар телендә беренче чыккан китаплар турында сөйли белү. Китапханәдә кирәкле материалны сорап ала белү. Үзеңнең яратып укыган китабың турында сөйли белү |

| | | |
|---|---|---|
| 17–20 | Татар музыка сәнгате үсеше.<br>Татар сынлы сәнгате үсеше | Татар музыка, сынлы сәнгате үсеше турында сөйли белү, диалоглар төзү. Сәнгатькә караган терминологияләрне әйтә белү |
| 21–23 | Теркәгечләр.<br>Татар музыка сәнгатендә күренекле шәхес – Александр Ключарёв.<br>Без А. Ключарёв турында сөйләшәбез.<br>Сорау алмашлыклары | Тезүче һәм ияртүче теркәгечләрне аера, тәрҗемә итә, җөмләләрдә куллана белү.<br>Композитор А. Ключарёв турында сөйли, диалоглар төзи белү |
| 24–27 | Бөек рәссам Х. Якупов.<br>Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы.<br>Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | Бөек рәссам Х. Якупов турындагы текстны сәнгатьле уку, кирәкле мәгълүматны таба, диалоглар төзи, сөйли белү.<br>Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча сөйләшү.<br>Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен таба, тыныш билгеләрен куя белү |
| 28–30 | Тезмә кушма җөмләләр.<br>Якташыбыз, талантлы композитор София Гобәйдуллина.<br>Без София Гобәйдуллина турында сөйләшәбез | Теркәгечле һәм теркәгечсез кушма җөмләләрне аера белү.<br>«Якташыбыз София Гобәйдуллина» текстын сәнгатьле уку, кирәкле мәгълүматны таба, диалоглар төзи, сөйли белү |
| 31–33 | Татарстанда театр сәнгате үсеше.<br>«Татар театры» тексты.<br>Күренекле драматург Туфан Миңнуллин турында сөйләшәбез.<br>III зат берлек һәм күплек сан боерык фигыльләрнең барлык-юклык формасы | Театр сәнгатенә караган лексик-грамматик материалны тәрҗемә итә белү, истә калдыру. Текстны сәнгатьле уку, кирәкле мәгълүматны таба белү. Казандагы театр исемнәрен атый белү.<br>Татар театры үсеше турында сөйли белү. Театрга барырга чакыра, билетларга заказ бирә белү.<br>Туфан Миңнуллин иҗаты турында диалоглар төзи, сөйли белү |
| 34–35 | Музыка сәнгате турында сөйләшәбез.<br>Иярченле кушма җөмләләр.<br>Баш җөмләгә иярчен җөмләне бәйләүче чаралар | Иярченле кушма җөмләләрне, баш җөмләләрне, иярчен җөмләләрне, аларны бәйләүче чараларны аера белү.<br>Бергә концертка бару, нинди музыка, артистларны ярату турында диалоглар төзи, сөйләшә белү |
| 36–39 | Без татар сәнгате турында сөйләшәбез | Татар композиторлары, җырчылары, рәссамнар, театр артистлары, татар музыкасы турында, Татарстанда чыккан газета-журналлар, Казандагы яңа театр бинасы турында сөйләшә белү |

| **Һөнәр сайлау (28 сәгать)**<br>**III. Мир моих увлечений** | | |
|---|---|---|
| 40–42 | Исем ясагыч кушымчалар.<br>Без һөнәрләр сайлыйбыз.<br>Теләк фигыль | Исем ясагыч кушымчаларны ялгап һөнәр исемнәрен әйтә белү. Төрле һөнәр ияләренең хезмәтен әйтә белү. Әти– әниләрнең кем булып эшләве, кем буласың килү турында сөйләшү |
| 43–44 | Һөнәр сайлау – җаваплы эш.<br>Урта махсус уку йортлары | Һөнәрләр темасына караган лексик материалны тәрҗемә итә белү, истә калдыру. Әти–әниләрнең һөнәрләре турында сөйләшә белү. Яңа һөнәрләр, үзеңә ошаган һөнәрләр, яраткан һөнәрне сайлау турында әңгәмә кора белү |
| 45–46 | Исем фигыль.<br>Һөнәр сайлауга таләпләр.<br>Мин кем булып эшләргә телим? | Һөнәр сайлауга таләпләр турында сөйләшү. Кем булып эшләргә теләвеңне әйтә белү |
| 47–48 | Хезмәт базары. Хезмәт базарында ихтыяҗ.<br>Урын һәм охшату-чагыштыру рәвешләре | Яңа һөнәрләр, нинди һөнәрләргә ихтыяҗ зурлыгы турында сөйләшү. Уңышлы һөнәр сайлау шартлары турында әңгәмә кора белү |
| 49 | Без эшкә урнашабыз | Эшкә урнашканда кулланыла торган типик диалогларда сөйләшә белү |
| 50–51 | Иярчен шарт җөмлә.<br>«Гомәр һәм һөнәр» шигыре | «Гомәр һәм һөнәр» шигырен сәнгатьле уку, әсәрнең төп проблематикасын ачыклау.<br>Иярчен шарт җөмләне сөйләмдә куллана белү.<br>Төрле һөнәрләрнең авыр якларын сөйли белү |
| 52–54 | Иярчен вакыт җөмләле кушма җөмлә.<br>Без эшкә урнашабыз | Иярчен вакыт җөмләле кушма җөмләләрне аера, тәрҗемә итә, сөйләмдә куллана белү. Яшүсмерләрнең эшкә урнаша алу вакыты, рөхсәт ителгән хезмәт төрләре турында әңгәмә кора белү |
| 55–57 | Хикәя фигыльнең заман формалары.<br>Укытучы һөнәре. Минем яраткан укытучым.<br>Иярчен сәбәп җөмлә | Хикәя фигыльнең заман формаларын аера, тәрҗемә итә, сөйләмдә куллана белү.<br>Укытучы һөнәре, укытучы һөнәренә таләпләр турында сөйли белү. Яраткан укытучың турында сөйли белү.<br>Иярчен сәбәп җөмләне сөйләмдә куллана белү |

| | | |
|---|---|---|
| 58–59 | Татар телендә килешләр.<br>«Килешләр» шигырендәге лексик-грамматик материал.<br>Киләчәк укытучысы – ул нинди? | Татар телендә килешләрне атый, исемнәрне килешләр белән төрләндерә белү. «Киләчәк укытучысы» турында фикерләр әйтә белү |
| 60–62 | Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәре.<br>«Табибта» темасы буенча сөйләшәбез | Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәре турында белешмә бирә белү. «Табибта» темасы буенча әңгәмә кора белү. Табиб һөнәренә хас сыйфатлар турында сөйләшү |
| 63–65 | Иярчен максат җөмләле кушма җөмлә.<br>«Хезмәткә хөрмәт» темасындагы лексик-грамматик материал.<br>Игенче һөнәре турында сөйләшәбез | Иярчен максат җөмләле кушма җөмләләрне аера, тәрҗемә итә белү.<br>«Хезмәткә хөрмәт» темасы буенча әңгәмә кора белү |
| 66–67 | «Ипи кирәк» шигыре | «Ипи кирәк» шигыре буенча әңгәмә кора белү. Игенче хезмәтен ихтирам итү турында сөйли белү |
| **Сәламәтлек – зур байлык (11 сәгать)<br>I. Мир моего «Я»** | | |
| 68–70 | Сәламәтлекне саклау кагыйдәләре.<br>Гаджетомания – зарарлы гадәт | Интернетка, компьютер уеннарына бәйлелекнең зарары турында әңгәмә кора белү |
| 71–72 | Исем фигыльнең килешләр белән төрләнеше.<br>Зарарлы гадәтләр | Тәмәке тартуның зарары турында сөйли, әңгәмә кора белү |
| 73–74 | Эчкечелек авыруы | Эчкечелек авыруының зарары турында сөйли, әңгәмә кора белү |
| 75–76 | Ак үлем | Наркоманиянең сәбәпләре, зарары турында сөйли, әңгәмә кора белү |
| 77–78 | Эмоциональ интеллект.<br>Эмоциональ интеллектка ия шәхеснең төп сыйфатлары.<br>Эмоциональ интеллектны яхшырту юллары | «Эмоциональ интеллект» төшенчәсенең нәрсә икәне, эмоциональ интеллектка ия булу кешегә ничек тәэсир итүе, эмоциональ интеллектлы шәхесләрнең нинди уңай сыйфатлары барлыгы, эмоциональ интеллектны ничек яхшыртырга мөмкин булуы турында әңгәмә кора белү |

| | | |
|---|---|---|
| **Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый (24 сәгать)**<br>**IV. Моя Родина** | | |
| 79–82 | 9 нчы Май – Җиңү бәйрәме.<br>Татарстан уллары, Советлар Союзы геройлары.<br>Юклык алмашлыклары | Татарстан уллары, Советлар Союзы геройлары турында әңгәмә кора белү.<br>«Беркем», «бернәрсә», «беркайчан» юклык алмашлыкларын сөйләмдә куллана белү.<br>Җиңү көне, сугыш барышы, сугышта катнашучы ветераннар турында әңгәмә кора белү |
| 83–84 | «Әсирлектә туган дуслык» текстындагы лексик-грамматик материал.<br>Шарт фигыль | «Әсирлектә туган дуслык» текстындагы лексик-грамматик материалны үзләштерү.<br>Шарт фигыльне сөйләмдә куллануны камилләштерү |
| 85–87 | Әсирлектә туган дуслык | М. Җәлилнең төрмәдә А. Тиммерманс белән очрашуы турында әңгәмә кора белү |
| 88–91 | Җәлилчеләр – М. Җәлилнең Моабит төрмәсендәге көрәштәшләре | М. Җәлилнең Моабит төрмәсендәге көрәштәшләре турында әңгәмә кора белү |
| 92–93 | Юклык алмашлыклары.<br>Муса Җәлилнең «Дуска» шигыре | Муса Җәлилнең героик тормышы, җәлилчеләр, «Моабит дәфтәрләре» циклы турында диалоглар төзи, сөйләшә белү. «Дуска» шигыренең фәлсәфи мәгънәсе турында әңгәмә кора белү |
| 94 | Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланова турындагы тексттагы лексик-грамматик материал | Советлар Союзы Герое М. Сыртланова турындагы тексттагы лексик-грамматик материалны үзләштерү |
| 95–97 | Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланованың батырлыгы | Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланованың батырлыгы турында әңгәмә кора белү |
| 98 | Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин турындагы тексттагы лексик-грамматик материал | Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин турындагы тексттагы лексик-грамматик материалны үзләштерү |
| 99–102 | Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинның батырлыгы | Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинның батырлыгы турында әңгәмә кора белү |

## Ишетеп аңлау күнегүләре

### Татарстан икътисады
### 1–3 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ү].**

Дәүләт, күп, мул, ут, яшәү, күпмилләтле, гомумән, туган.

**2. Прослушайте и укажите слова, состоящие из одного слога.**

Төс, дәүләт, дан, бай, юл, як, хокук, җир, мул, күп, таң, һава, ил, тел, ак, йөк.

**3. Прослушайте и подберите к данным словам антонимы.**

Эссе, бай, матур, чыкты.

**4. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому существительному прилагательное.**

… як, … юл, … таң, … табигать, ... дәүләт, ... республика, ... җиребез, ... елгалар, ... таулар.

**5. Прослушайте и переведите на татарский язык.**

Татарстан – многонациональная республика. Тут проживают представители более 100 национальностей. Площадь нашей республики составляет 68 тысяч квадратных километров.

**6. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Республикабызның үз символикасы бар.

Республикабызның үз символикасы бар: Дәүләт флагы, гербы, гимны.

2) Татарстан флагында өч төс бар.

Татарстан флагында өч төс бар: яшел, ак, кызыл.

3) Татарстан чит илләргә йөк автомобильләре чыгара.

Татарстан чит илләргә йөк автомобильләре, сәгатьләр, суыткычлар, автомобиль шиннары, мех әйберләре, дарулар, җылылык үлчәү приборлары чыгара.

**7. Прослушайте диалог и постарайтесь повторить его с соседом по парте.**

– Син нинди республикада яшисең?

– Мин Татарстан Республикасында яшим.

– Республикагыз аша нинди елгалар ага?
– Республикабыз аша Кама, Идел, Нократ, Агыйдел елгалары ага.
– Татарстан күпмилләтле республикамы?
– Әйе, Татарстан – күпмилләтле республика.

### 4–8 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с твёрдым произношением.**
Үсеш, табигый, чыганак, үзәк, өлеш, Спартак, тасма, горурлык, байлык.

**2. Прослушайте и укажите слова с мягким произношением.**
Җиңел, җитәкче, дөнья, урын, фабрика, химия, танылган, җитештерә.

**3. Прослушайте и составьте словосочетания, подбирая нужные слова.**
Йөк …, машина ..., химия ..., җиңел ..., азык-төлек ..., акционерлык ... .

**4. Прослушайте и переведите.**
1) Татарстанда машина сәнәгате, химия сәнәгате, җиңел сәнәгать, азык-төлек сәнәгате үскән.
2) КАМАЗда чыгарылган йөк машиналары Европа, Азия, Африка, Латин Америкасы илләренә сатыла.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Республиканың иң үскән икътисади юнәлешләре булып нефть-газ химиясе комплексы: … .
2) Республикада машиналар төзү эре предприятиеләре … .
3) Татарстанда 2030 елга кадәр республиканы фәнни-техник яктан … .
4) Татарстан Республикасының яңа икътисади тармакларын формалаштыру … .

### 9–11 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с твёрдым произношением.**
Кара, алтын, байлык, көн, үзәк, өлеш, чит, бүген, җитештерелә, мазут, бензин, ягулык.

**2. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Татарстанның иң зур байлыгы – ... .
2) Нефть беренче мәртәбә ... .
3) Татарстанда бүгенге көндә 3 миллиард тоннадан артык ... .

**3. Прослушайте и укажите слово, логически не связанное с другими.**

Вертолёт, машина, мазут, бензин, тун, нефть.

**4. Прослушайте и составьте словосочетания, подбирая нужные слова.**

Табигый ..., чит ..., кара ..., химия ... .

**5. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Татарстан бүгенге көндә 3 миллиард тоннадан артык нефть чыгаруга иреште.

Татарстан 3 миллиард тоннадан артык нефть чыгаруга иреште.

2) Татарстанда чыгарылган нефтьнең күп өлеше Россиягә һәм чит илгә җибәрелә.

Татарстанда чыгарылган нефтьнең күп өлеше Россиягә җибәрелә.

3) Түбән Камада нефтьтән мазут, бензин һәм дизель ягулыклары җитештерелә.

4) Түбән Камада нефтьтән мазут, бензин җитештерелә.

**6. Переведите на татарский язык.**

Елабуга, Нижнекамск, Бугульма, Ромашкино, Бавлы, Азнакаево, Альметьевск, Чистополь.

## 12–14 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите двусложные слова.**

Музыка, корал, мирас, җырчы, концерт, артист, театр, язучы, язмыш, гармун.

**2. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Лев Толстой, Сергей Аксаков, Максим Горький, Александр Пушкин, Василий Аксёнов.

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайда?***

Музыкант, җыр, сәнгатьтә, концерт, Зур театрда, дөньяда, югары.

**4. Прослушайте и ответьте на вопросы.**

– Республикабыз нинди күренекле мәдәният эшлеклеләренең тормышы белән бәйле?

– Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры кайларда чыгышлар ясый?

– Казанда нинди халыкара кино фестивале үткәрелә?

– Татарстан Республикасы нинди тарихи мираска ия?

**5. Прослушайте и закончите предложения.**

1) ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән тарихи истәлекләрнең ... . 2) Казан Кремлендә урнашкан тарихи архитектура истәлекләре: ... . 3) Болгар шәһәре Идел буе ... . 4) Свияжск утрау-шәһәренә Явыз Иван ... . 5) Кол Шәриф мәчете ... .

## 15–16 нчы дәресләр

**1. Прослушайте слова и попробуйте повторить весь список слов.**

Тел, китап, гарәп, хәреф, манифест, хөрмәт, китапханә.

**2. Прослушайте и измените слова по образцу.**

О б р а з е ц : *Күлмәк – күлмәгем.*

Китап, китапханә, шәһәр, тел.

**3. Прослушайте начало диалога и продолжите.**

– Айдар, син нинди китапханәгә йөрисең?

– Мин шәһәр китапханәсенә йөрим. Ә син?

**4. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Мин китапханәгә язылырга ... . 2) Айдар китапханәгә беренче тапкыр ... . 3) Алия китапханәгә еш ... . 4) Мин маҗаралы китаплар укырга ... . 5) Безнең өйдә зур китапханә ... .

## 17–20 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ң].**

Сәнгать, үзенең, нигез, җырчы, атаклы, горурлана, милләт, моң, тыңлады, күңел, сынлы.

**2. Прослушайте и укажите слова, состоящие из одного слога.**
Нигез, салучы, иҗат, опера, төркем, портрет, әсәр, яшь, чын, моң.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**
Җырчы, композитор, рәссам, сатучы, скульптор, язучы.

**4. Прослушайте и подберите к данным словам антонимы.**
Ачыла, көн, зур, кертә, киң.

**5. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения: *минем, синең, аның.***
Халык, музыка, театр, җыр, дәүләт, әсәр.

**6. Прослушайте и подберите к существительным подходящие прилагательные.**
... рәсем, ... сәнгать, ... өлеш, ... җыр, ... дәүләт, ... исем, ... музыкант, ... әсәр

**7. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Татар музыка сәнгате … . 2) Татар милли балетына нигез ... . 3) Татар халкының яраткан җырчылары – ... . 4) Татар сынлы сәнгатенә нигез салучы – ... . 5) Бакый Урманче сыннар да, портретлар да ... .

**8. Прослушайте диалог и перескажите.**
– Марат, син татар музыка сәнгатенә нигез салучылардан кемнәрне беләсең?
– Салих Сәйдәшев, Александр Ключарёв, Җәүдәт Фәйзи, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһановларны беләм.
– Ә Нәҗип Җиһановның нинди әсәрен беләсең?
– «Алтынчәч», «Җәлил» операларын беләм.
– Бу операларны театрда тыңлаганың бармы?
– Әйе, тыңлаганым бар.

**9. Прослушайте и скажите, кто из этих людей композитор, а кто художник.**
Салих Сәйдәшев, Александр Ключарёв, Бакый Урманче, Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Илдар Зарипов, Җәүдәт Фәйзи, Фәрит Яруллин, Мансур Мозаффаров, Нәҗип Җиһанов, Садри Ахун, Виктор Кудelькин, Рада Нигъмәтуллина.

## 21–23 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с мягким произношением.**

Күренекле, сәүдә, кадер, уңыш, атказанган, сәнгать, яшь, көй, сөекле, танылган.

**2. Прослушайте и укажите количество слогов в словах.**

Тәрбияле, әдәбият, сәләт, яңгырый, зыялы, милли, гармун, моң.

**3. Прослушайте и переведите слова на татарский язык.**

Обычаи, распевает песни, мелодия, творчество, силы, не хватает сил.

**4. Прослушайте, повторите слова и составьте с ними предложения.**

Балык тоту, көймәдә йөрү, ял итү, балалар тәрбияләү.

**5. Прослушайте и переведите предложения на татарский язык.**

Александр Сергеевич Ключарёв – заслуженный работник искусства России и Татарстана, народный артист Республики Татарстан, лауреат Государственной премии имени Габдуллы Тукая Республики Татарстан.

Отец Александра Ключарёва, Сергей Данилович работал счетоводом в большом торговом доме, а мать, Надежда Семёновна воспитывала дома детей.

У Саши рано открывается музыкальный талант. В 5 лет он уже играл на гармони. Когда учился в гимназии, он играл на скрипке и пианино.

## 24–27 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ү].**

Якупов, үзенең, разведчик, дөнья күрә, сугыш, Ватан, күбрәк, старшина, күргәзмә, дәүләт, иҗат, өлкә, Кабан күле.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем, синең, аның.***

Ватаным, күргәзмәсе, сәнгате, әсәрләрен, иҗаты, картиналары.

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишли?***

Катнаша, күзәтә, тәмамлый, сәнгать, әсәрләр, яза, ясый, бирелә.

**4. Прослушайте и скажите на татарском языке.**
1) Харис Якупов – народный художник Татарстана.
2) Он участвовал в Великой Отечественной войне.
3) Картины Хариса Якупова «Озеро Кабан», «На Волге» знакомы многим.
4) В 1976 году он был удостоен премии И. Репина.

**28–30 нчы дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**
Дөнья, остаз, гаҗәп, нәсел, сәләт, талантлы, әсәр, җир, аягүрә, уңыш.

**2. Прослушайте и назовите глаголы во 2 лице единственного числа.**
Утыра, саклый, җитәкли, гаепли, ирешә, аралаштым, төзи, үстерә.

**3. Прослушайте и определите главные члены предложения.**
Ул талантлы шагыйрьләр белән аралашып яши. Талантлы композитор симфоник әсәрләр иҗат итә. Аның таланты бөтен дөнья халкын таң калдыра.

**4. Прослушайте и выделите предложение, которое не соответствует теме.**
София Гобәйдуллина – танылган шәхес. Ул тамашачыларга камера музыка остасы һәм кинога музыка язган композитор буларак та таныш. Чаллыда сәнгать йолдызларының зур концерты булып үтте. Атаклы скрипкачы Кремер София Гобәйдуллинаның «Корбан» әсәре белән бөтен җир шарын әйләнә.

**5. Прослушайте и скажите, кто из этих творческих людей композитор.**
Александр Ключарёв, Илһам Шакиров, Сара Садыйкова, Әлфия Авзалова, Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин, Зөфәр Билалов, София Гобәйдуллина, Равил Шәрәфиев, Харис Якупов, Җәүдәт Фәйзи.

**31–33 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ң].**
Сәнгать, тәҗрибә, талант, моң, күңел, сәләт, яшь, тамаша, мәдәни, баш.

**2. Прослушайте и повторите слова, добавляя ним местоимения *минем, синең, аның*.**

Театр, күңел, моң, тәҗрибә, сәләт.

**3. Прослушайте и скажите, как изменились бы аффиксы этих глаголов, если бы действия не происходили.**

Теләп килә, күрсәтелә, уйный, яза, ярата, дәвам итә, барабыз, карыйбыз, мактый, йөри.

**4. Прослушайте и переведите.**

1) Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры.

2) Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры.

3) Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры.

**5. Прослушайте начало диалога и продолжите его.**

– Рамилә, әйдә иртәгә театрга барабыз.

– Ә нинди театрга?

– ...

**6. Прослушайте начало предложения и закончите его.**

1) Татарларда театр сәнгате ... . 2) 1906 нчы елның 22 нче декабре ... . 3) Театрның горурлыгы – ... . 4) Татар театры тарихында тирән эз калдырган атаклы шәхесләр: ... . 5) Туфан Миңнуллин ... .

## 34–39 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [р].**

Музыка, корал, җырчы, концерт, артист, эстрада, ансамбль, гармун.

**2. Прослушайте, назовите глаголы во 2 лице единственного числа, переведите и составьте с ними предложения.**

Музыка яратам, гармунда уйныйсың, җыр тыңлыйлар, концерт карыйсыз, биергә яратасың.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Курай, гармун, скрипка, баян, җыр, пианино.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

Моңлы, тиз, сәнгатьле, гаҗәп, моң, көчле, җыр, сәләтле, концерт, зыялы, сөекле.

**5. Прослушайте и перескажите содержание диалога.**

– Ләлә, бүген «Җиде йолдыз»ның финал концерты була. Син барасыңмы?

– Минем барасым килә, Лена. Ә синең барасың киләме?

– Минем дә барасым килә. Талантлы артистлар чыгыш ясыйлар бит.

**6. Прослушайте и скажите, кто из этих творческих людей певцы.**

Илһам Шакиров, Лотфулла Фәттахов, Зәйнәп Фәрхетдинова, Сара Садыйкова, Салават Фәтхетдинов, Зилә Сөнгатуллина, Әлфия Авзалова, Салих Сәйдәшев, Ренат Ибраһимов, Бакый Урманче, Зөфәр Билалов, Равил Шәрәфиев, Гөлнара Тимерҗанова.

## Һөнәр сайлау

### 40–42 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**

Тарих, тәрбия, матур, тел, укытучы, тәрҗемәче, галим, иген, җиләк-җимеш.

**2. Прослушайте и укажите слова с ударением на второй слог.**

Һөнәр, һәрвакыт, хөрмәт, өлкән, имтихан, пешекче, сатучы, күңел .

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишләми?***

Язмый, эшли, тыңламый, эшләми, сөйләми, укымый, бара, хөрмәт итә.

**4. Прослушайте и переведите на татарский язык.**

